# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Дәвек торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында**

**30 ноябрь 2022ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 30.11.2022 гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча халык җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Дәвек торак пунктында яңа скважина кору (материаллар сатып алу, койма кою, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Дәвек торак пунктындагы су башнясына насос сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 228 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 117 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 117 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга: Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Дәвек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 2500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку

буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш

- Дәвек торак пунктында яңа скважина кору (материаллар сатып алу, койма кою, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Дәвек торак пунктындагы су башнясына насос сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы: ____________З.С.Гәрәева
(имза)